УМАРТАЧЫ ХӘЗРӘТ

«Хәләл акча булмаса, хаҗга барып булмый»

> 2

УКЫГАЧ ЭШЛИСЕ

Юллама буенча эшкә урнаштыру кадрлар кытлыгын киметерме?

> 3

ЧАЛГЫҢНЫ КАЙРА!

Печән чабар вакыт килеп җиткәнен сизми дә калды авыл кешесе

> 4

ВИРТУАЛЬ ПӘРӘВЕЗ

Без интернет колы түгелме?

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 68 (29035) | Чәршәмбе | 17 май | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Эльвира ВӘЛИЕВА

ЭШЛЕ ҺӘМ АШЛЫ ҖЫЕН

КАЗАНГА 15 МЕҢНӘН АРТЫК КУНАК КИЛӘ

kazan.ruc.su

Вакыйга

Елның иң зур вакыйгасы! Татарстан Министрлар Кабинетында узган брифингта бу атнада узачак «Россия – ислам дөньясы: KazanForum 2023» XIV Халыкара икътисадый форумын әнә шулай дип бәяләделәр. Аның республика өчен ни дәрәҗәдә әһәмиятле булуы да билгеле.

Кунакчыл Казан

Бу атнада Татарстан башкаласында узачак «Россия – ислам дөньясы: KazanForum 2023» XIV Халыкара икътисадый форумында 15 меңнән артык кеше катнашырга теләк белдергән.

– Бу – рекорд сан. Казанга илнең 84 төбәгеннән һәм 85 чит илдән кунаклар киләчәк, – диде Татарстанның Инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесе Талия Миңнуллина.

Билгеле булганча, быелдан Россия Президенты Владимир Путин тәкъдиме белән икътисадый җыен федераль статус алды. Шуңа күрә дә агымдагы елда форумда катнашырга теләк белдерүчеләр бермә-бер арткан. Чагыштыру өчен, былтыр Казанда узган икътисадый җыенда 6400гә якын кеше катнашкан булган.

Башкалада узачак чараның әһәмияте һәм аның нәкъ менә бездә үткәрелүен форумда катнашучыларга юллаган сәламләү хатында Владимир Путин да ассызыклады. «Татарстан башкаласы чираттагы мәртәбә киң колачлы, эшлекле чаралар үткәрү өчен кирәкле һәм абруйлы мәйдан статусын раслап, күп кенә илләрдән килгән кунакларны киң колач җәеп каршы ала», – диде ул.

Телефоннан сөйләшү барышында, Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнехановка Төрекмәнстан Халык Мәсләхәте башлыгы Гурбангулы Бердымөхәммәдов та Казанда булачак форумның иң югары дәрәҗәдә узачагына ышаныч белдерде. Ул җыенга Төрекмәнстаннан вәкиллекле делегация җибәрүен хәбәр итте.

САН

Рәсми мәгълүматларга караганда, **2023** елның беренче өч аенда гына да Татарстаннан Казахстан, Азәрбайҗан, Белоруссия, Үзбәкстан, Кытай, Вьетнам, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре, Кыргызстан кебек илләргә **3** миллион долларлык хәләл продукция озатылган.

Кунаклар дигәннән, Татарстанга һәм бездә узачак чарага кайсы илләр күбрәк кызыксыну белдергәне дә билгеле.

– Чит илләрне әйтсәк, йөз кешедән дә күбрәк булган иң зур делегацияләр Азәрбайҗан, Иран, Малайзия, Таҗикстан, Төркия һәм Үзбәкстаннан киләчәк. Ил төбәкләре арасында иң күп катнашучылар Санкт-Петербург, Мәскәү шәһәрләре, Оренбург, Самара өлкәләре, Чечня, Башкортстан, Мордовия республикаларыннан теркәлгән, – диде Талия Миңнуллина.

«Соңгы тапкыр мондый хәл Казанда футбол буенча дөнья чемпионаты узганда булган иде...» Башкаладагы кунакханә хуҗалары әнә шулай ди. Казанда кунакханәләрдә урыннар беткән. Бу җәһәттән журналистлар, кунаклар урамда калмасмы, дип тә борчылу белдерде. Спорт һәм социаль проектлар дирекциясе генераль директоры Максим Денисов әйтүенчә, мондый хәл булмаячак.

– Форум көннәрендә башкаладагы өч, дүрт, биш йолдызлы кунакханәләр йөз процентка тулды. Моңа сөенмичә дә мөмкин түгел. Димәк, форум белән кызыксыналар, безгә киләләр. Казандагы икътисадый җыен бик зур тарту көченә ия, – диде ул.

Татарстан мисалында

Форум кысасында 200дән артык эшлекле, мәдәни, белем бирү һәм спорт чарасы узачак дип көтелә. Төп сөйләшүләр ислам финанслары һәм хәләл индустриясенә бәйле булачак, әлбәттә. «Без Татарстан мисалында ислам бизнесы белән хезмәттәшлек итү алымнарын җайга салырга телибез. Ислам икътисады үсеше өлкәсендә бик зур мөмкинлекләр ачыла. Аерым алганда, хәләл ризык индустриясе, хәләл туризм, хәләл медицина үсә», – дип белдерде рәсми чараларның берсендә Татарстан Рәисе.

«KazanForum»да имзалау өчен 100дән артык килешү әзерләгәннәр инде.

– Чараның нәтиҗәлелеге имзаланган килешүләрнең эчтәлеге һәм саны белән бәяләнә, әлбәттә. Без якынча 100 килешү имзаларга ниятлибез. Аларның саны күбрәк булырга да мөмкин. Аларның иң зурлары Төньяк-Көньяк халыкара транспорт коридорына бәйле. Мәсәлән, Татарстанда җитештерелгән техниканы Үзбәкстанга озату, Азәрбайҗанда «Sollers» компаниясе сәнәгатен җәелдерүгә бәйле килешүләр бар, – диде ул. – Форумны үткәрә башлаганнан бирле, быел иң күп килешү имзаланачак дип көтелә.

Җитәкче икътисадый форумның республикадагы кече һәм урта бизнес өчен дә әһәмиятле булуын әйтте.

Мәйсәрә гарәпчә сөйләшә

Җитди сөйләшүләр белән генә булмый, әлбәттә. Форум кунакларын эш белән генә түгел, күңел ачу чаралары белән дә шаккатырмакчылар. Җыен көннәрендә Казан «Агропаркы»нда «Russia Halal Market 2023» ярминкәсе эшләячәк. Аның урыны очраклы гына түгел. Бу теләге булган һәркем бирегә килеп җитә алсын һәм хәләл ризык, кием-салым сатып алу мөмкинлегенә ия булсын өчен эшләнгән. Ярминкәгә керү бушлай.

Ахыры 2 нче биттә >

Урманнар яңартыла

Быел язын Татарстанда урманнарны яңарту эшләре 1523,1 гектар мәйданда, ягъни планда күздә тотылганча башкарылган. 1413,5 гектар мәйданда киселгән яки корыган-янган агачлар урынына яңалары утыртылган, 105,6 гектар мәйданда урманнар үстерелгән. Эшләр «Экология» илкүләм проектының «Татарстанда урманнарны саклау» төбәк проекты кысасында алып барыла.

Урман хуҗалыгы министры Равил Кузюров әйтүенчә, 2023 елда республикада «Экология» илкүләм проекты буенча 3614 гектар мәйданда урманнар торгызылачак. 2092 гектар мәйданда урманнарны табигый торгызуга (кискәннән яки янганнан соң агачларның үсеп чыгуы шулай дип атала) ярдәм итәчәкләр. Бу эшләр җәйге-көзге чорда башкарылачак.

Министр республикада агач орлыклары һәм үсентеләр запасының аерым игътибар үзәгендә тотылуын белдерде. Бер ел эчендә 11455 кг орлык һәм 30863 үсенте әзерләп куярга ниятлиләр.

Төзүчеләр – дүртенче

Илдар Мөхәммәтҗанов

Татарстан быел 4 айда файдалануга тапшырылган торак мәйданы буенча Россия төбәкләре арасында дүртенче урынга чыккан. Росстат билгеләп үткәнчә, шушы вакыт эчендә республикада барлыгы 1411600 квадрат метр торак мәйданы кулланышка кертелгән. Бары тик Мәскәү өлкәсе (3,9 млн кв. м), Мәскәү (2,5 млн кв. м) һәм Краснодар крае (2,4 млн кв. м) күрсәткечләре генә безнекеннән югарырак дәрәҗәдә. Бишенче урында – Ленинград өлкәсе (1,2 млн кв. м).

Сүз уңаеннан, төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры Марат Айзатуллин хәбәр иткәнчә, республикада торакны файдалануга тапшыру буенча еллык планның 45,5 проценты үтәлгән. Бигрәк тә коммерцияле торак төзүчеләр тырыша: планның 47 процентын үтәгәннәр.

Баладан чирен яшермә!

Бүгенгә Татарстанда ВИЧ-инфекцияле 148 бала теркәлгән. ВИЧ-инфекцияле кешеләргә ярдәм итү фонды җитәкчесе Светлана Изамбаева «Татар-информ» хәбәрчесенә сөйләп үткәнчә, бары тик 76 бала һәм үсмер генә үзенең авыруы турында белә. Калганнарына әти-әниләре бу хакта әйтүдән баш тарткан.

«Әниләр һәм әбиләрдән еш кына, дус-ишләргә сөйләсәк, башкаларга ычкындырулары бар, яки әле бәләкәй ул, берни аңламый, дигәнрәк сүзләр ишетергә туры килә. Ләкин авыр нәтиҗәләргә китерергә мөмкин бу. Үзенең чирен белмәүче балалар ни өчен көн саен дару эчәргә кирәклеген аңламый. Ә дару эчми ярамый, чөнки дәваланмаган очракта ВИЧ-инфекция СПИД стадиясенә күчә», – дигән фонд җитәкчесе.

Росстат мәгълүматларына караганда, йогышлы авырулардан үлем-китем очракларының яртысы ВИЧ-инфекциягә туры килә. Үсмер дару эчмәгән очракта гомере буе инвалид булып калырга яки вафат булырга мөмкин.

Яшәргә өйрәнәбез

Алганга бирәләр

Бу елның апреле автомобиль сатучыларга уңыш китергәндер. Ник дигәндә, апрель ае нәтиҗәләренә карасак, банклардан халыкка бирелгән автокредит күләме соңгы ун ел эчендәге рекордлы күрсәткечкә җиткән. Сан белән әйтсәк, 110 млрд сум бу!

Frank RG экспресс-мониторинг үзәге мәгълүматларына караганда, автокредитның уртача хакы да рекордлы булган – 1,42 млн сум. Чагыштыру өчен: 2022 елның февралендә автокредит чегы 1,4 млн сумга җитәр-җитмәс булган.

Frank RG белгече Станислав Сухов белдергәнчә, автокредит бирү базары акрынлап кына яңа һәм кулланылган машиналар сегментында да үсешен дәвам итә. Ел азагын фаразласак, белгеч әйтүенчә, машина базары 2021 елгы күрсәткечләргә җитәргә мөмкин. Ул елны 1,1 трлн сумга 935,3 мең автокредит рәсмиләштерелгән булган икән.

Кайбер белгечләр искәрткәнчә, уңайлы шартларда эшләвен дәвам итсен өчен, машина базарына озаграк вакыт та кирәк булуы ихтимал. Әйтик, яңа «тимер атлар» сатып алу өчен ташламалы кредит программалары, базарны Кытай брендлары белән тутыру, илнең үзендәге җитештерүчәнлеген арттыру. Параллель импорт әлегә Россия базарыннан киткән маркалы автомобильләргә ихтыяҗны өлешчә генә канәгатьләндерә, дип ассызыклыйлар.

Сүз уңаеннан, ташламалы автокредит программасы быел да гамәлдә булачак. Аны гаиләдә 18 яше тулмаган кимендә бер бала тәрбияләүче кешеләр, табиб, укытучы, хәрбиләр һәм тәүге тапкыр машина сатып алырга җыенучылар куллана ала. Моңа өстәп, бу мөмкинлек алты елдан «зуррак» машиналарны «трейд-ин» шартларында



shutterstock.com

тапшыручыларга да бирелә. Шарты: кимендә бер елдан артык әлеге машинаның хуҗасы булып тору кирәк. Дәүләт автомобильнең 20 проценты күләмендә ташлама бирәчәк. Шунысын да искәртергә кирәк: әлеге программада барлык банклар да катнашмый.

Узган ел ташламалы автокредит программасында Lada, «УАЗ», «ГАЗ»ның барлык модельләре, шулай ук Кытайның Haval Jolion кроссоверы катнашкан иде. Быел программаның төп «ат»ы булып «АвтоВАЗ» калачак.

АВТОКРЕДИТ БИРҮ ДИНАМИКАСЫ



Чыганак: Frank RG

Сүзгә-сүз

Рамил МУЛЛИН, Түбән Кама шәһәре мэры:

Дәүләт, кеше үзенең сәламәтлеген кайгыртсын өчен, диспансеризациягә күп акча сарыф итә. Әгәр дә без 80–90 яшьлек кешеләрне югалтабыз икән, бу – бер нәрсә. Сүз дә юк, без аларны яратабыз, югалтырга теләмибез. Ләкин без 40, 50 яшьтәгеләрне югалтабыз. Тикшерә башлагач, аларның хәтта диспансеризация дә үтмәгәннәре ачыклана.

(«Эшлекле дүшәмбе»дәге чыгышыннан)

ТАТАРСТАНДА – КЕШЕ САНЫ

4 001 625

2023 ел башына Татарстанда яшәүчеләр саны

100 ИР-АТКА >> **114** ХАТЫН-КЫЗ

Ир-атларның уртача гомер озынлыгы >> **69,8 яшь**

Хатын-кызларның уртача гомер озынлыгы >> **79,8 яшь**

25 мең кеше бара

Быел Россиядән Мәккә һәм Мәдинә шәһәрләренә хаҗга баруга 25 мең урынга квота билгеләнгән. Россиянең Ислам хезмәттәшлеге оешмасы каршындагы даими вәкиле Рамазан Абдулатыйпов «РИА Новости» хәбәрчесе белән әңгәмәсендә белдергәнчә, мөселманнарның хаҗ кылу өчен Согуд Гарәбстанына барып кайтуына бәйле берниндидә кыенлык юк. Корольлек хаҗилар өчен кирәкле барлык шартларны тудырачак.

Дипломат билгеләп үткәнчә, хаҗга бару Россия хаҗ миссиясенең Согуд Гарәбстаны белән үзара тыгыз хезмәттәшлеге нигезендә оештырыла. Аның әйтүенчә, хаҗга баруны оештыру һәм хаҗ кылуны тәэмин итү эше, төрле яктан уйланып, бик дөрес алып барыла.



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ФӘЛӘСТЫЙНДА ТАГЫН КАН КОЕЛА

Глобаль дөньяда турбулентлык үсә. Кызганыч, без сәяси күзәтүләргә багышланган һәр язманы шундый рухта башларга мәҗбүрбез. Дәүләтләр арасындагы мөнәсәбәтләр, икътисад һәм социаль тармак көннән-көн сикәлтәлерәк була бара, баш әйләндергеч зур трамплинга якынлаша. Зур сикәлтәдән очып төшкәндә егылмый калу мөмкинлеге кимегәннән-кими. Нью-Йоркның Федераль резерв банкы белгечләре, АКШ икътисадының әйләнеп каплану ихтималы якындагы 12 ай эчендә 40 еллык максимумда, дигән нәтиҗәгә килгәннәр. Кара сценарийның тормышка ашу мөмкинлеге 68,2 процент дип исәпли алар. Чагыштыру өчен сан китерик. 2007 елның ноябрендә андый мөмкинлек 40 процент кына дип исәпләнгән. 2008 елгы зур кризис шундый саннар артыннан башланып киткән.

Гаҗәпләнмик: бер АКШта гына түгел, башка илләрдә дә дәүләт әҗәтләре түләп бетерә алмаслык дәрәҗәдә үсә. Италия Үзәк банкы дәүләт әҗәтенең тарихи рекорд куюын – 2,79 триллион еврога җитүен хәбәр итә. Бурычның үсеш темплары санның үзенә караганда да куркынычрак. Соңгы өч айда ул триллион евродан күбрәккә арткан. Бирәчәк андый темплар белән артса, ниләр буласын чамаларга мөмкин.

Бу юллар язылганда, Фәләстыйн халкының трагедиясенә – Нәкбәгә (безнеңчә, фаҗига, катастрофа) 75 ел тулды. 1945 елның 15 маеннан башлап Фәләстыйн гарәпләренең масштаблы эзәрлекләнүе һәм канлы югалтулары дәвам итә. Шул чор эчендә 800 меңнән артык фәләстыйнлы этник чистартуларга дучар ителгән, меңләгән гарәп үтерелгән (70 массакүләм үтереш исәпләнә), 531 авыл юк ителгән. Израильнең беренче премьер-министры Давид Бен-Гурион: «Картлар үләр, яшьләр онытыр», – дисә дә, мазлум халыкның үз хокуклары өчен көрәше тукталмый. Канлы юбилей алдыннан вазгыять тагын кискенләште. Дөнья җәмәгатьчелеге даими кабатланып торучы кан коелуларга күнекте инде. Прогрессив җәмәгатьчелекнең, кыерсытылган халыкны якларга тырышып, БМО структуралары аша аны якларга омтылуы АКШ ветосына очрый. Сионистларның бомбага тотуларына гарәпләр кулдан ясалган ракеталар һөҗүме белән җавап бирәләр. Мәшһүр «Тимер гөмбәз» һава һөҗүменә каршы тору системасы ул ракеталарны гадәттә бәреп төшерә, гадәттән тыш сирәк очракларда гына алар максатларына барып җитә иде. Соңгы дуэльдә гарәпләр сыйфат ягыннан зур сикереш ясады. Хакерлар «Тимер гөмбәз»нең программасына һөҗүм иттеләр һәм аны өзделәр. Беренче тапкыр үлем һәм җәрәхәтләнү очраклары артты. Берничә тапкыр килешү турында игълан ителсә дә, үзара кан коеш кабатланды. Ике як та үзен җиңүчеләр дип игълан итте. Газзәдәге соңгы бәрелеш бер нәрсәне искәртә: сугыш кырында ай-ти технологияләр торган саен киңрәк кулланыла һәм зур сәнәгать тарафыннан җитештерелгән технологик коралларны бернигә яраксыз итә алалар. Бу цивилизациягә глобаль куркыныч янавын – бер селтәнүдә барлык казанышларның юкка чыгарылу ихтималын хәбәр итә. Төп кораллар ук һәм җәядән торырга мөмкин дигән сүз бу.

Россиядә

УРТАК БЮДЖЕТ: КЕРЕМНӘР ҺӘМ ЧЫГЫМНАР

Россия федераль бюджетының дефициты кискен үскән чорда яшибез. Бу безгә быел булмаса, киләсе елга зур проблемалар вәгъдә итә. «Чыгымнар нәрсәгә тотыла?» дигән сорау туа. Салым түләүчеләрдә андый сорау барлыкка килү бер дә гаҗәп түгел, чөнки ил бюджетында гына түгел, гаилә бюджетларында да җитмәүчелек арта. Соңгы көннәрдә товар һәм хезмәтләр куллану үсә икән, бу – нигездә кредит бирүнең артуы нәтиҗәсе.

2022 елның мартыннан Финанс министрлыгы дәүләт чыгымнарының структурасын игълан итүдән туктады. Әмма белгечләр электрон бюджет аша чыгымнарның күпме булуын һәм кая китүен исәпләп чыгара барыбер. Консолидацияләнгән бюджетны (ягъни федераль һәм төбәк бюджетларын бергә кушкач килеп чыккан саннарны) өйрәнгәч, объективлыкка якын картина туа. 2022 елда бердәм бюджет чыгымнары 55,1 триллион сумны тәшкил иткән. Бу – эчке тулай продуктның 17 проценты, 2021 ел белән чагыштырганда чыгымнар 8 триллионга күбрәк. Арту рекордлы. Әмма үткән ел бюджет профицитлы булды, чөнки нефть-газ бәяләренең котырып үсүе акча яудырды.

Бездә төп чыгымнар оборонага һәм силовикларга тотыла дигән фикер нык бит инде. Чынлап та, федераль бюджетта аларга чыгымнар елдан-ел арттырыла. Ләкин консолидацияләнгән бюджет өстенлекнең социаль өлкәдә икәнен раслый. Үткән ел социаль сәясәткә (пенсияләр, пособиеләр, ана капиталы, льготалар һ.б.) 17,8 триллион сум акча тотылган. Милли икътисад 8,4 триллион сумны йоткан. Монысы да социаль өлкәгә якын аның, чөнки юл төзелеше, авыл хуҗалыгы, транспорт, элемтә тармакларын үз эченә ала. Мәгарифкә 5,5 триллион сум бүленгән. Сәламәтлек саклау тармагы да шулкадәр үк суммадан файдаланган. Болар барысы да халык мәнфәгатьләренә хезмәт итә. Оборона – 5,5 триллион сум, хокук саклау тармагы 2,2 триллион сум акча белән финансланганнар.

2023 елда чыгымнар үсеше темпы артты. Бюджет профицитлыдан дефицитлыга әйләнде. Дефицит хәтта бюджетка салган параметрлардан күпкә узып китте. Оборона чыгымнары 3,9 тапкыр артып киткән, диләр белгечләр. Сүз гыйнвар – февраль чыгымнары турында гына бара. Ел башында күбрәк булып, башка кварталларда, бәлки, ул чыгымнар кими торгандыр. Без кулда булган саннар белән генә эш итәбез. 2002 елның беренче ике аенда оборона чыгымнары бюджет структурасында бишенче урында гына булса һәм уртак бюджетның 8,5 процентын гына тәшкил итсә, 2023 ел башында, социаль сәясәттән генә калышып, икенче урынга күтәрелгәннәр һәм алар өлеше 23,3 процентка (!) җиткән.

РӘИС КӨНДӘЛЕГЕ

ЯҢАРТКАННЫ САКЛАУ МӨҺИМ

Җәмәгать урыннарын булдырыр алдыннан, алар урнашачак җирне яхшылап өйрәнергә, халыкның теләге белән кызыксынырга кирәк. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов республиканың шәһәр һәм районнарында яшәүче җитәкчеләр, хезмәткәрләр өчен оештырылган укулар барышында шулай дип белдерде.

Рәис җәмәгать урыннары булдыру буенча 2015 елдан бирле гамәлдә булган программаларны халык өчен мөһим сорауларга җавап дип атый.

– Әйләнә-тирә мохит иҗтимагый аң формалаштыра. Шуңа күрә без ел саен парк һәм скверларны, яр буйларын, комлыкларны, урам һәм мәйданчыкларны яңартабыз. Ишегалларын да төзекләндерә башладык. Бу проектларны тормышка ашыруда җирле халык та катнашырга тиеш. Җәмәгать урыннарында тормыш кайнарга тиеш. Шуңа күрә булдырыр алдыннан, алар урнашачак җирне яхшылап өйрәнергә, халыкның нәрсә күрергә теләве белән кызыксынырга кирәк, – ди Рөстәм Миңнеханов.

Саннар теленә күчсәк, соңгы сигез ел эчендә Татарстанда барлыгы 367 җәмәгать урыны һәм күпфатирлы йортлар арасында урнашкан 3 мең 379 ишегалды төзекләндерелгән.

– Яңа объектлар барлыкка килү шәһәр һәм бистәләребезгә яңа төсмер бирә. Бу урыннар җирле халык белән туристлар арасында да популярлаша. Төзекләндерелгән объектлар тирәсендә тормыш кайнавын күрү бик рәхәт, анда төрле чаралар уза, кызыксынулар буенча төрле берләшмәләр пәйда була. Монда яңа сервис һәм хезмәтләр кертүче үзенчәлекле индустрия, спорт һәм яшьләр берләшмәләре дә тартыла, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Татарстан Рәисе төзекләндерелгән объектларны саклап тотарга кирәклеген дә искәртте. Бу урыннар ял итү һәм эшмәкәрлек белән шөгыльләнү өчен дә яхшы җирлек булырга тиеш, дигән фикердә ул.

tatarstan.ru

– Без җәмәгать урыннарын төзекләндерү белән генә чикләнмичә, аларны дөрес итеп идарә итә дә белергә тиеш. Бу республиканың иң ерак төбәкләрендә дә уңай үзгәрешләргә китерәчәк, – дип саный Рөстәм Миңнеханов.

Җәмәгать урыннары белән эшчәнлеккә багышланган укулар өч көн дәвам итәчәк. Анда катнашучыларга Россиянең башка төбәкләреннән килгән белгечләр дә белем бирәчәк. «Укулар тәмамлангач, кулыгызда гамәлдәге паркларны яңарту өчен кирәкле барлык белем-күнекмәләр булачак. Командалы эш барышында яңа уй-фикерләр дә килергә мөмкин. Җәмәгать урыннарында шуларның бер өлешен быелгы җәйдә үк гамәлгә ашырачакбыз», – ди Рөстәм Миңнеханов.

Эшле һәм ашлы җыен

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Биредә Иран эчемлекләре, Төркия тәм-томнары, Сенегал кием-салымы да сатып алып булачак хәтта. Бу хакта Татарстан авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары Рөстәм Гайнуллов әйтте. Хәләл ярминкә үткәрү өчен «Агропарк»ны тулысынча юып чыгарганнар. 20 майга кадәр биредә 400дән артык хәләл сәүдә ноктасы эшләячәк.

– Төп басым Татарстанда җитештерелүче продукциягә ясалачак. Чөнки без республиканы чит илгә хәләл продукция озатучы төбәк буларак күрсәтергә телибез, – диде урынбасар.

Форум кунакларын башкала театр, музейларында да көтәләр. Җыен көннәрендә Камал театрында, мәсәлән, «Зәңгәр шәл»не күрсәтәчәкләр. Спектакль инглиз һәм гарәп телләренә дә тәрҗемә ителәчәк. «Казан Кремле» музей-тыюлыгы дивары үзе бер зур экранга әйләнәчәк. Биредә утлы тамаша күрсәтәчәкләр.

– Мәдәни чараларга теләге булган һәркем килә ала, – дип тә искәртте Татарстан мәдәният министры Ирада Әюпова. – Без җыен кунаклары өчен киңкырлы программа әзерләргә тырыштык. Гомумән алганда, әлеге чара безнең бай мирасыбыз белән горурлану өчен тагын бер мөмкинлек булып тора.

«KazanForum» белән бергә Казанда унөченче Бөтендөнья татар дин әһелләре форумы да узачак. Аның эшендә илнең 77 төбәгеннән 1 меңгә якын кеше катнашачак. Ә 21 майда Татарстан кунакларын Изге Болгар җыенында көтәләр. Билгеле булганча, быел халыкка үзенчәлекле күргәзмә тәкъдим ителәчәк: Болгар җиренә пәйгамбәребезнең (с.г.в.) ун ядкаре кайтарылачак. Бәйрәм чаралары иртәнге сәгать тугызда башлана.

– Кайбер делегация вәкилләре, изге җирдә басып дога кылу өчен, Казанга гаиләләре белән килә, – дип сөйләде Бөтендөнья татар конгрессының башкарма комитеты җитәкчесе Данис Шакиров. – Без исә Татарстанда башкарылган эшләр белән тагын бер кат горурлана алабыз.

Илдар Мөхәммәтҗанов

ҮЗЕБЕЗНЕҢ САНДУГАЧ

«Ул сәхнәгә чыкканда, халык басып алкышлый иде. Кара чәчле, чибәр егет, ә тавышы...» Профессиональ татар эстрадасына нигез салган Рәшит Ваһаповның тууына – 115 ел. Шул уңайдан Казанда мәшһүр җырчының һәйкәле янында митинг-концерт узды.

Әйтергә кирәк, тантаналы чарага шактый халык җыелган иде. Араларында танылган язучылар, шагыйрьләр, җырчылар, театр артистлары һәм башкалар бар. Бәйрәм Ваһапов фестивале лауреатлары һәм Татарстанның Дәүләт җыр һәм бию ансамбле чыгышы белән башланып китте.

– Үз шәхесебез Рәшит Ваһаповны Татарстанда гына түгел, күп өлкәләрдә, республикаларда, чит илләрдә дә бик яраталар иде. Хәзер дә яраталар. Истә тотабыз, Аллага шөкер. Былтыр бик матур итеп һәйкәл ачтык. Хәзер шушында халык җыела. Бу күбесенчә – заманында Рәшит Ваһапов белән очрашкан, күргән, аның җырын тыңлап үскән буын. Яшьләребез дә күп килә, монысы да бик шатландыра, – диде тантанада Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин. – Күпмилләтле халкыбыз, Рәшит Ваһапов җырларына җанын-тәнен биреп, мәгънәсен аңлап, берләшеп, матур итеп яшәде һәм яши. Үз халкыңа һәм иҗатка чиксез мәхәббәт Рәшит Ваһаповның тормыш юлының нигезе булды. Аның һәр җыры йөрәккә үтеп керә. Мәскәүдә татар операсы студиясен тәмамлап кайткан Татарстан филармониясе солисты үзенең көчле, матур тавышы, халык җырларын кабатланмас башкаруы белән тамашачы күңелен әсир итте. Халык аны тиз арада «үзебезнең сандугач» дип атый башлады. Мәдәни мирасыбызга әйтеп бетергесез өлеш керткән татар моңының асылташы ул Рәшит Ваһапов.

Казан Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Гүзәл Сәгыйтова әйтүенчә, Ваһапов буыны җырчылары бүген дә яшьләргә юл күрсәтүче маяк булып тора.

– Казаныбызда барыбызны да бер фикергә туплаган, Рәшит Ваһапов иҗатына гына түгел, ә татар җырына дан җырлаган мәйдан барлыкка килүгә без бик шатбыз. Әлбәттә, ул үзеннән-үзе тумады. Шушы һәйкәлнең барлыкка килүенә күп көч куйган Ваһапов фонды җитәкчесе Рифат Әхмәт улы Фәттаховка зур рәхмәт. Әйдәп йөрүчеләр һәрбер эштә кирәк, – диде Гүзәл Сәгыйтова. – Яшь җырчыларны күреп сөенәбез. Ваһапов буыны җырчылары бүген дә безнең яшьләргә юл күрсәтүче маяк булып тора. Шул җырларның саклануы – иң мөһиме. Җырлар җырлана, яшьләр тарафыннан татар теле саклана икән, димәк, без киләчәккә өмет тулы күзләр белән карыйбыз.

Ләйсән САФИНА

ОТАР ӨЧЕН, КЫЗЫКСЫНУ КИРӘК

Авыл капкасы

Яшел Үзән районындагы Мамадыш-Әкил авыл җирлегендә сыер, кәҗә һәм сарык көтүләре бетеп килә. Зур терлек тотуның файдасы бик юк, ди халык. Шуңа өстәп, соңгы елларда умартачылык белән шөгыльләнүчеләр саны да кимүгә таба бара. Әйтик, моннан берничә ел элек 40лап хуҗалыкта умарта булса, хәзер исә өч-дүрт йортта гына бал суырталар. Алар арасында Камил хәзрәт Камалов та бар. Ул 50 баш умарта асрый.

Камил хәзрәт – тумышы белән Кайбыч районындагы Салтыган авылыннан. Умартачылык эше ата-бабаларыннан килгән, дисәң дә була. 1978 елда ул Кама Тамагы районының Тәмте (Теньки) авылындагы һөнәр училищесын тәмамлаган. Яшел Үзән районына кайтып, колхозда башта ярдәмче булып эшләгән. Аннан соң тормыш иптәше Фирая апа белән бергә умарта асрый башлаган. Казанда, Рязань өлкәсендә укып, умартачы һөнәрен үзләштергән. «Шуннан бирле кортны бетергәнебез юк», – ди Камил хәзрәт.

Аның сүзләренчә, язның иртә килүе бал кортларына зыян салмаган. Киресенчә, умарталары ишәйгән генә: биш яңа бал корты гаиләсенә артканнар. Бал төрләренә килгәндә, әйләнә-тирәдәге басуларга башлыча көнбагыш чәчелгәнлектән, бөҗәкләр балны нәкъ менә шуларның чәчәкләреннән җыя.

– Ул әле июльнең урталарында гына чәчәк атадыр. Ә юкә якынча 5–12 июльдә. Әмма юкә урманы бездән ерак, өч чакрым юл чамасы. Шулай да анысы да булыр дип өметләнәбез. Кортлар оча, эзләнә. Гомумән алганда, балның кайсы гына төре булса да, файдалы. Кызганыч, соңгы елларда бал кортлары арасында да төрле авырулар чыккалап тора, шуңа күрә кешеләр кортчылыктан читләшә, – ди умартачы.

Умартачылыктан тыш Камил аганың кызыксынулары шактый. Ул сарык үстерү белән дә шөгыльләнә. Мәчет эшен дә алып барырга вакыт таба. Нәтиҗәсе дә куанычлы. Бүген Камаловлар ихатасында 50 баш умарта, 45 баш «Романов», «Курдюклы» токымлы сарык, биш кәҗә асрала. Ә инде кечкенә тавыклар, куяннар, күркәүрдәкләргә килсәк, аларның саны бихисап. Сарыкларны исә Корбан бәйрәменә, бәби чәйләренә сатып алалар, ди.

Камил хәзрәт Фирая апа белән мәктәп вакытыннан ук бергә. Пар канатлы гаиләдә ике бала тәрбияләгәннәр. Уллары икесе бер көндә Самара өлкәсе Чапаевск шәһәренә хезмәт итәргә киткәннәр. Хәзер исә өлкәннәре Айнур үз гаиләсе белән Осиноводан кунакка кайтып йөри. Ә кече улы Илнур Ерак Көнчыгыш космодромында эретеп ябыштыручы булып эшли.

Камил хәзрәт бер олы хаҗга, ике тапкыр кече хаҗга барып кайткан. Ул 2013–2015 елларда Казанның «Ислам динен кабул итүнең 1000 еллыгы» исемендәге Казан урта мөселман мәдрәсәсен читтән торып тәмамлаган. Шуннан соң инде сигез ел имам-хатыйп вазыйфасын башкара.

Илдар Мөхәммәтҗанов

– Сарык тотмасаң, корт асрамасаң, хәләл акча булмаса, хаҗга барып булмый. Шушы акча белән 2017 елда олы хаҗга барырга туры килде. Аннан соңгы елда кече хаҗга барып, шуннан бераз тынычланган идем инде. Хаҗ гамәлләрен аңлатып бетереп булмый. Үзе күрмәгән кеше аны аңлый да алмый, – дип сөйли Камил хәзрәт. – Табыш төрле елны төрлечә була. Берьюлы ике тармакны алып барырга кирәк: бер елны бал булса, икенче елны сарыклар күбәеп китә. Балыңны сатып, шул акчага сарыкларга арпа, печән, салам аласың. Шулай итеп, зыян сизелми, керем генә була. Әгәр бер тармакны гына алып барсаң, әйтик, сарык кына асрасаң, керем дә азрак була. Ә инде кош-корт һәм вак терлек асрау күңел өчен генә, бу – безнең хобби.

Ел саен җәй көне, август аенда алар бал бәйрәме ясыйлар. Урамда зур өстәлләр көйләп, кичен авыл эшләреннән соң урамны утлар белән яктыртып, бөтен кешеләрне чакырып күңел ачалар. Кайберәүләр гармуннар белән менә, элеккеге татар җырларын җырлый, кыскасы, бу бик күңелле була.

Диана КАРПОВА

БЕР МАНДАТЛЫ САЙЛАУ ОКРУГЫ БУЕНЧА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫНА ӨСТӘМӘ САЙЛАУГА ТЕРКӘЛГӘН КАНДИДАТЛАРНЫҢ САЙЛАУ АЛДЫ АГИТАЦИЯСЕ МАТЕРИАЛЛАРЫ

МАТЕРИАЛЛАР АВТОР ЭШКӘРТҮЕНДӘ БАСТЫРЫЛА. АЛАРНЫ ГАЗЕТА БИТЛӘРЕНДӘ УРНАШТЫРУ БАСМА МӘЙДАН БҮЛҮ БУЕНЧА ҮТКӘРЕЛГӘН ЖИРӘБӘ НӘТИҖӘЛӘРЕНӘ ТУРЫ КИЛӘ

**№ 20 Электротехник
бер мандатлы сайлау округы**

Теркәлгән кандидат Нигъмәтуллин Р.Р.
Агитация материалы. Татарстан Сайлау кодексының 62 маддәсе нигезендә бушлай бастырыла.

**№ 20 Электротехник
бер мандатлы сайлау округы**

Теркәлгән кандидат Вахитов А.Р.
Агитация материалы. Татарстан Сайлау кодексының 62 маддәсе нигезендә бушлай бастырыла.

Чемпионнар янәшәсендә

Спорт

Көрәш, уңыш, бәхет, омтылыш һәм казаныш. Татарстанның Чаңгы узышлары федерациясендә «кубок»ны шул сүзләрнең беренче хәрефләреннән төзелгән дип аңлыйлар. Берничә көн элек республика чаңгычылары узган сезонга йомгак ясады. Катлаулы, аның каравы мавыктыргыч булды ул.

Татарстан чаңгычылары быел алтынчы тапкыр Россия Кубогын яулады. Безнекеләр мондый уңышка бишенче ел рәттән ирешә. Гадәти хәл кебек. Әмма быелгысының кыйммәте тагын да зуррак. Ник дигәндә, дөнья күләмендә танылган чемпионнар, ягъни Большунов, Устюгов һәм башкалар моңа кадәр мәртәбәле халыкара ярышлардан кайтып керми иде. Спорт дөньясындагы мәгълүм вакыйгалар аркасында, быел алар үзебездә генә көч сынашты. Нәтиҗәдә Россиядәге ярышларда көндәшлек дәрәҗәсе бермә-бер артты. Шуңа карамастан, Татарстан чаңгычылары янә Россия Кубогын яулады. Республика чаңгычылары барлыгы 7 алтын, 23 көмеш, һәм 24 бронза медаль иясе булып танылды. Аерым спортчыларның осталыгыннан бигрәк, команда рухы ярдәмендә.

Безнекеләрне котларга килгәч, Россиянең Чаңгы узышлары федерациясе президенты, Олимпия чемпионы Елена ханым Вяльбе да әйтте бу сүзләрне.

– Татарстан җыелма командасында башкалардан бер башка өстен булган лидерлар юк. Көчле егетләр карьерасын тәмамлый, өметле кызлар әле үз көчен күрсәтә алмый. Спортчылар тиз үсми. Әмма Татарстанда игътибарны җәлеп иткән исемнәр бар инде. Сездә Большуновлар юк, аның каравы

vk.com/Роман Кручинин

бердәмлек белән алдырасыз. Россия Кубогын алтынчы мәртәбә оту – республикада чаңгы спортының тотрыклы үсеше билгесе. Сездә күпме баланың чаңгыда йөргәнен беләм. Күпмедер вакыттан соң бу спортта да нәтиҗәсен бирәчәк, – диде ул тантанада. Чаңгыда җиңгән, өйрәткән һәм идарә иткән кеше белми әйтмәс.

Татарстанның Чаңгы узышлары федерациясе президенты Илшат Фәрдиев тә быелгы җиңүне күмәк эш нәтиҗәсе дип атады. «Безгә ышандылар, ә егетләр һәм кызлар өметләрне аклады», – диде ул.

ЮЛ КҮРСӘТҮМЕ?

Мөнәсәбәт

Вуз тәмамлагач, өч елга – мәҗбүри эшкә! Бюджет бүлегендә укыган егет-кызларга кагыла бу. Күптән түгел Татарстан Дәүләт Советы депутатлары Дәүләт Думасына әнә шундый закон проекты тәкъдим иткән иде. Тәкъдим хупланырмы – әлегә билгесез. «ВТ» хәбәрчесе эшкә юллау мәсьәләсенең уңай һәм тискәре якларын белеште.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Закон проекты яшьләрне эш урыннары белән тәэмин итү, оборона-сәнәгать предприятиеләрен кадрлар белән тәэмин итү, илнең икътисадын үстерүне күздә тота. Юллама буенча эшкә барырга риза булмаганнарга исә дәүләт акчасын кире кайтарырга туры киләчәк. Әлеге тәкъдимне хуплаучылар да, каршы килүчеләр дә бар.

Казандагы 15 нче татар гимназиясе директоры Фәнит Харисовны заманында Саба районының Шармыш мәктәбенә юллама буенча эшкә җибәргәннәр. Ике ел укытканнан соң директор вазыйфасын тапшыралар.

– Бу тәкъдимне искелек калдыгы димәс идем. Мәктәпләргә кадрлар җитми. Элек күп укытучылар шулай төпләнеп калды бит. Дәүләт моны кабул итсен иде, – ди Фәнит Харисов.

Буа районының Адав-Толымбай авылында яшәүче Альбира апа Камартдиновага да юллама буенча эшкә барырга туры килгән. Ул үзе – Әгерҗе районы кызы. Буа техникумында белем алган.

– Эшеңне яратып башкарсаң, сине хөрмәт итсәләр, шуннан да кадерлерәк әйбер юк. Укыганда кияүгә чыктым. Мине күрше авылга эшкә билгеләделәр. Өч ел ярым үткәч, иремнең авылындагы ятимнәр интернат-мәктәбенә шәфкать туташы булып кайттым. Юллама буенча эшкә җибәрүнең бернинди начар ягын күрмим. Кеше үзе яшәгән җирнең кагыйдәләрен хөрмәт итсә, юллама белән эшкә барырга тиеш дип уйлыйм, – ди Альбира апа.

Арча районының Наласа авыл җирлеге башлыгы Илфира Шакирова әйтүенчә, яшьләр вузларның авыл хуҗалыгы, медицина юнәлешләрендә максатчан программа буенча белем алып, авылга эшкә кайта. Яшь белгечләргә яңа йортлар да салганнар.

– Балалар әти-әни фикере белән вуз, көллиятләргә укырга керә. Аны тәмамлагач, бер сәгать тә эшләмичә, кибетче яки башка белгечлекне сайлый. Беренчедән, укыткан укытучыларның хезмәте югала. Әгәр мәҗбүри булса, мондый проблема булмас иде, – ди ул.

Түбән Кама эшмәкәре Илнар Сираев яшь белгечләрне каядыр эшкә җибәрүне үткәнгә кайту дип санамый. Аның фикеренчә, бу – яшьләргә акча эшләү өчен мөмкинлекләр тудыру дигән сүз.

– Мин әле дипломны яшь белгеч предприятиедә бер ел эшләгәч кенә бирүне кертер идем. Дүрт ел бушка укымаганын күрсәтү өчен кирәк бу, – ди эшмәкәр. – Юллама белән эшкә җибәрүне хуплыйм. Шулай булырга тиеш тә! Бюджет хисабына укыганнар белем өчен түләсен. Ким дигәндә өч ел эшләү кирәк. Теләмиләр икән, дәүләткә чыгымнарны кире кайтарсыннар. Әйтик, студентлар берәр белгечлек буенча укыйлар да аннан менеджер булып урнашалар. Алай булгач, нигә ул һөнәргә укып торырга? Армиядән калу өченме әллә? Җитәкчеләр исә яшьләргә шартлар тудырырга тиеш. Берничек тә булышмаганда, әлбәттә, китәчәкләр.

Өлкәннәр юллама буенча җибәрүне хупласа да, яшьләрнең карашы башкача.

Кукмара районының Ядегәр мәктәбен тәмамлаган Инсаф Фәйзрахманов КФУда программист белгечлеген үзләштерә. Хәтерләсәгез, ул БДИдан 393 балл (!) туплаган иде. Инсаф инде эшкә дә урнашкан, әмма юллама белән каядыр бару яклы түгел. Мәҗбүр итәргә кирәкми, ди.

– Махсус операция башланганнан бирле эш табу авыр. IT белгечләр буенча вакансияләр юк. Кечкенә компанияләр ябылып бетте. Тәҗрибәң булмаса, син бөтенләй беркемгә дә кирәк түгел. Дуслардан чыгып әйтәм. Аларның компанияләре ябылып, ел буе эш таба алмыйлар. Мин авылда яки районда эшләмәс идем. Ник дигәндә, хезмәт хакы күпкә кимрәк булачак, – ди Инсаф.

Ике ел элек вуз тәмамлаган Илүзә Мәхмүтова мәҗбүриләү яшьләрнең иреген кыса дип саный. Корректор хезмәтен сайлаган Илүзә юллама буенча каядыр эшкә барырга риза түгел.

– Укучылар ничә ел буе бөтен көчен БДИга әзерләнүгә багышлый. Аларның үзе теләгән уку йортына кереп, үзе теләгән җирдә эшлисе килә. Бик сирәк яшьләр авылга кайту ягын карыйдыр, минемчә. Күбесе шәһәрдә, бигрәк тә зур шәһәрләрдә калырга тели. Шуны максат итеп, тырышып, бюджет урыннарына укырга керәләр. Ә бу закон проекты аларның бөтен эшләгәнен, киләчәген җимерә кебек. Түләп укырга мөмкинлекләре булмаган студентлар үзләре теләмәгән җирдә эшләргә мәҗбүр булачак бит. Моның киләчәктә тискәре яклары килеп чыгарга мөмкин, чөнки тормыштан канәгатьлек дәрәҗәсе кимеячәк, – ди Илүзә Мәхмүтова.

Фикер

Никита ФИЛИППОВ, Әгерҗе егете, Россия Президенты каршындагы Россия халык хуҗалыгы һәм дәүләт хезмәте академиясе студенты:

– Татарстан Дәүләт Советы тәкъдимен төрле яктан карарга мөмкин. Кадрлар җитмәү – мөһим проблема. Әлеге закон проекты – аны хәл итү өчен яхшы ысул. Әмма югары уку йортларын тәмамлаучылар арасында, совет заманындагы кебек, юллама буенча җибәрү белән килешүчеләр аз булыр дип уйлыйм. Студентлар өчен хәзер мөмкинлекләр күп һәм сайлау хокукы булырга тиеш. Хәзерге вакытта һәр абитуриент файдалана алырлык максатчан квота бар. Бүген илдәге югары уку йортларында максатчан урыннарны арттыру, квоталар бирү белән кызыксынуны арттыру кулайрак булыр.

Сәрия МИФТАХОВА

КОТЛЫЙБЫЗ!

Ветеринария өлкәсендәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләүләре өчен «Азнакай районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесе җитәкчесе – баш ветеринария табибы **Әхмәтшин** Рөстәм Муфаздал улына; «Апас районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесе җитәкчесе урынбасары – ветеринария табибы **Галиуллин** Нәгыйм Закир улына Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Россия Федерациясенең атказанган ветеринария табибы»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Гаилә институтын ныгытудагы һәм балалар тәрбияләүдәге казанышлары өчен **Әхмәдишин** Рөстәм Линар улы һәм **Фазлыева** Гөлнара Заһит кызы **Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә «Ата-ана даны» ордены медале** белән бүләкләнделәр.

ЯСАЛМА АКЫЛ НИ БЕЛӘН ЯНЫЙ?

Булмас димә

Ясалма акыл буенча белгечләр киләсе елларда аның искиткеч тизлек белән үсәчәген фаразлыйлар. Алар уйлавынча, без адәм акылы белән чагыштырырлык, хәтта аннан да өстенрәк гомуми ясалма интеллект хасил булачак көннәргә якынлашабыз.

Стэнфорд университеты профессоры Шейн Легг фикеренчә, ясалма интеллект кеше акылы дәрәҗәсенә 2025 елда ирешәчәк. Башка белгечләр бу чик 2030 нчы елларда булырга мөмкин дигән фикердә. Гомуми ясалма интеллект ул очракта мөстәкыйль өйрәнү һәм камилләшү тизлеген берничә тапкыр арттыра алачак.

Ләкин ясалма акыл өлкәсендәге алгарыш, һичшиксез, яңа проблемалар да китереп чыгара. Шуларның киң җәмәгатьчелекне иң нык борчыганы – эш урыннарына бәйле мәсьәләләр. Һәм бу урынсыз түгел. Үзгәреш кайсы өлкәләргә кагылырга мөмкин соң?

– Күп тапкырлар кабатланучы бертөрле хәрәкәтләрдән торган һөнәрләр. Сәркатип, телевидение алып баручысы, склад хезмәткәрләре.

– Шәхси ярдәм күрсәтү өлкәсе хезмәткәрләре. Һәртөрле графиклар төзү, отчетлар тутыру, клиентлар белән бәйләнешкә керү һ.б. шөгыльләргә бәйле һөнәрләрдә ясалма акыл нәтиҗәлерәк булырга мөмкин.

– Күзәтчелек мәсьәләләре. Хезмәт нәтиҗәләрен, эшчеләрнең үз-үзен тотышын, тәртибен, нәтиҗәлелеген һәм хәтта эмоциональ халәтен күзәтү һәм анализлауга бәйле һөнәрләр.

Монысы бик күп даирәләрдә шау-шу тудыра, хезмәт кешесен контрольдә тоту, аның белән идарә итү көчәеп киткән очракта, бу чынлап та бик четерекле вакыйгаларга сәбәпче була ала. Һәм ясалма акылның кешелек дөньясы белән идарә итүе дә шушы адымнардан башланырга мөмкин.

– Иҗат эшчәнлегенә бәйле кайбер һөнәрләр. Хис-тойгыларга кагылышлы мәсьәләләрдә ясалма акыл кешедән күпкә калышса да, иҗатның күп төрләрен ул алыштырырга мөмкин. Әйтик, фотография, дизайн, видео төшерү, музыка бизәү, тәрҗемә, хәтта төрле сайтлар өчен сатучы- һәм сео- текстлар язу өлкәсендә ул инде бүген үк шактый югары дәрәҗәдә. Ул бүген төрле оешмаларның социаль челтәрләрен алып барырга да сәләтле.

Саный башласаң, бик күп җыела. Хәтта ясалма акыл белән хезмәттәшлек итү, нәтиҗәлерәк эшләү өчен дә бик күп хезмәткәрләрне яңадан әзерләү таләп ителәчәк.

! Ясалма акылның кешене хәвефкә салучы мөмкинлекләре эш урыннары белән генә чикләнми әле. Бөтен хикмәт аның кемнәр кулына эләгүенә һәм нинди максатларда файдалануына бәйле.

Аның күзәтү һәм идарә итү мөмкинлекләре турында алдарак искәрттек инде. Хезмәт нәтиҗәләрен арттыру, эш шартларын яхшырту өчен кулланылган очракта бик файдалы нәрсә. Әмма ул шәхесне тоталь контрольдә тоту, аның белән идарә итү максатында да файдаланылырга мөмкин. Бу очракта инде кешелек электр-көтүче биләмәсендәге сыер көтүеннән дә хәтәррәк хәлгә төшәргә, хәтта читләр ихтыяры белән гамәл кылучы зомбига да әйләнергә мөмкин. Инде бүген үк дөньядагы дәүләтләр хакимиятендә демократиядән тоталитаризм ягына авышу күренеше күзәтелә. Шундый хакимият кулына ясалма акыл кебек корал эләксә, аны кулланмыйча калуларына бернинди ышаныч юк.

Ул дәрәҗәгә үк җитмәгән очракта да икенче ягы бар. Капитализм чорында җәмгыятьне идарә итүче бер генә чын көч бар, ул – акча, капитал. Аңа ирешүнең иң үтемле юлы – сәүдә, сату. Сатып алучыны җәлеп итү, товар белән кызыксындыру, сатып алырга мәҗбүр итү һәм аннан соң даими клиентка әйләндерү буенча әллә кайсы өлкәләрнең әллә нинди атаклы галимнәре көч түгә. Моңа кагылышлы миллионнарча китаплар языла. Ясалма акыл менә бу мәсьәләдә дә сәүдә оешмаларына потенциаль клиентны сатып алучыга әйләндерү өчен хезмәт итә ала. Бу инде бүген үк күпмедер дәрәҗәдә эшли. Интернеттагы эзләгечтә берничә тапкыр, әйтик, «Лада» автомобиле эзләп карагыз. Нинди генә сайтка, социаль челтәргә керсәгез дә, интернетның кайсы почмагына барып поссагыз да, сезне шул «Лада» машинасы турындагы реклама эзәрлекләячәк. Менә бу да – ясалма акыл эшчәнлегенең бер чагылышы.

Шулай итеп, ул кешенең теге яки бу үзенчәлегенә, ихтыяҗына бәйле рәвештә, аңа фәкать кемнәрнеңдер максатына яраштлы мәгълүматны гына күрсәтергә, икенче төрле әйткәндә, объектив мәгълүматны чикләү нәтиҗәсендә аның сайлау һәм уйлау мөмкинлеген контрольгә алырга сәләтле.

Ясалма акылның, кешегә буйсынудан туктап, аны колга әйләндерү мөмкинлеге турында да күп сөйлиләр. Бу хакта фикерләр төрлечә: берәүләр мондый куркынычның чынга ашуына ышана, икенчеләр адәмне алыштырырлык бернәрсә дә юк дип уйлый. Беренче карашка, ике як та хаклы кебек. Чынлап та, кеше акылы ул төгәл исәп-хисап кына түгел бит инде, һәртөрле хис-тойгылар, ым-ишарәләр белән чуарланган акыл. Әгәр ул бергә эшләгән иптәшенә карап: «Әнә теге нине генә нитеп куй әле», – дисә, иптәше аны берсүзсез аңлый ала. Ә ясалма акыл тончыгып калырга мөмкин. Әлбәттә, бу – фараз гына. Ә чынлыкта ясалма акылның нинди үзгәрешләргә һәм үсешләргә сәләтле икәнен беркем дә белми. Хәтта шул өлкәдә эшләүче зур галимнәр дә бу матавыкның ни белән тәмамланачагын төгәл әйтә алмый.

Марат КӘБИРОВ

Ватан хакына

ЗӘЙТҮНӘ ЗАКИРОВА:
«Улымны догам сакласын!»

Берәү китә, берәү кайта. Махсус хәрби операциядә катнашучы егетләр туган якларга ике атналык ялга кайтуларын дәвам итәләр. 7–8 ай буе күрешмәгән ана белән бала, ир белән хатын, сөйгән ярлар, әтиләрен көткән сабыйларның хисләрен берәү дә аңлата алмастыр, мөгаен. Бик кадерле, зарыгып көткән очрашу бит бу!

Апас районы Кече Болгаер авылы егете Илнур Закиров та бу көннәрдә ике атналык ялга кайтты. Аның кайтуын апасы – язучы-журналист Гөлүсә Закированың социаль челтәрдәге сәхифәләреннән күзәттек. Илнурның әнисе Зәйтүнә апа белән элемтәгә кердек.

– Улыбыз махсус хәрби операциядә 7 ай хезмәт иткәннән соң ялга кайтты. Аны кабаттан кочаклап алу шатлыгын әйтеп тә, аңлатып та бетереп булмый. Украинага киткәнче күпләр махсус хәрби өйрәнүләр узды. Шулай туры килде: 3 көннән соң улыбызны ай буе күнекмәләр узганнар белән бергә озаттылар да. Нишлисең, илне сакларга кирәк бит. Бармыйм, димәде. Армиядә чакта Чечняда хезмәт иткән иде ул, – ди әнисе Зәйтүнә апа.

Илнурның баштарак хәбәре булмый. Соңрак үзенең исәнлеген әйтеп, шалтырата башлый. Шалтыратканда бөтен авыл хәлләрен белешә ул. Үзе сагынса да сиздерми. Әнисе исә лачындай егет тәрбияләп үстерүенә сөенә. Авылдан берүзе Ватан сагында бит!

– Без олырак яшьтә булгач, аннан да кайгыртып торды. Малларга печән кертү, ишегалдында кар көрәү турында да борчылып сораша иде. Ялга кайтасы көнен хәбәр иткәч, үзебезнең дә йокы качты. Бик көттек, – ди әнисе. – Улым олыгаеп киткән, йөзенә ирләрчә җитдилек кунган кебек. Бер дә зарланмый. Токмачлы ашымны сагынган, рәхмәтләр укып ашады. Күзләрем белән сөеп карап кына утырдым үзен. Нинди батыр егет үстергәнбез икән! Мине анда егетләр күтә, бар да яхшы булачак, Аллаһ ташламасын, дип кенә тора.

Илнурны авылдашлары да сагынып көткән. Кайткан көнне үк хәл белергә килгәннәр. 9 Майга багышланган митингка да чакырганнар. Анда барып та чыгыш ясап кайткан. Район башлыгы да очрашуга чакырган, аның кебек үк ялга кайткан егетләрне җыеп аралашкан.

– Район башлыгы бик игътибарлы, бәйрәм саен безгә котлау җибәрә. Казандагы Апас якташлар

җәмгыяте дә күчтәнәчләр китерә, аларга да рәхмәт. Улыбыз сугыштан бер кочак хатлар күтәреп кайткан. Гуманитар ярдәм белән килгән мәктәп балалары хатлары ул. Шуларны саклаган. Мин язып биргән догалар да үзе белән. Аллаһ саклар, бөтенләйгә кайтыр, – ди Зәйтүнә апа.

Закировларның дөньялары түгәрәк чак. Илнур үзе дә тормыш мәшәкатьләре, бәрәңге утырту, бәбкәләргә күл буенда читән кору ише вак-төяк, көндәлек эшләр белән мәш килә икән. Бу очрашуның һәр минуты кадерле. Әни күңеле сизә: тиздән газизе җиңү белән кайтачак. Башкача мөмкин дә түгел. Ананың һәр догасы шул хакта. «Илләр тыныч булып, һәр ананың баласы исән-имин кайтса иде», – ди Зәйтүнә апа.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Туңдыргыч кыйссасы

Уены-чыны бергә

Минем беренче хуҗам: «Кошларда да – кеше язмышлары...» – дип көйләп йөрергә ярата иде. Менә хәзер гараждагы баскыч астында ялгызым гына утырып торам, күңелсез инде, гел шул җыр искә төшә. Җитмәсә, караңгы, салкын... Күләргә ашыкмагыз. Туңдыргыч булсак та, салкында бик начар сизәбез без үзебезне. Дымлана, күгәрә башлыйбыз.

vk.com

Сүзем кошлар турында иде бит әле. Без дә шул кошлардан ким түгел икәнбез бит. Бездә дә – кеше язмышлары.

...Мин өр-яңа, ялтырап тора идем әле ул чакта. Заводтан чыгарып, Казанның бер кибетенә алып кайтып куйдылар. Хәтта складта да ятарга туры килмәде. Бер яшь кенә ханымның шундук күзе төште. Кухнялары кечкенә булганга, минем кебек бәләкәй туңдыргыч кирәк булган икән. Бик кадерләп, аш бүлмәсенең түренә кайтарып куйдылар. Суыткычтагы туңдыргычка җиләк-җимешләре сыймаган булган. И-и, тутырып куйдылар, минсиңайтим. Җиләк, чия, слива дисеңме... Ниләр генә юк. Ул хуш исләре! Яшим шулай хозурланып. Яз җиткәндә, җиләкләр беткәч, чистартып юып куялар. Мин дә кешеләр кебек җәйге ялга чыгып, рәхәтләнеп ял итәм.

Тик... хуҗаларымның яңа, зур фатир алулары бөтен тормышымны чәлпәрәмә китерде. Кухнялары да иркен булганга, зур туңдыргыч алып куйдылар да, миңа урын калмады. Шәһәр кырыенда йорт сала башлаганнар иде, шунда илтеп куйдылар. Мин инде, дөресен генә әйткәндә, барыбер җылыда, рәхәттә яшәрмен дигән идем. Кая ул! Әллә нигә бер килгәнгә, суыткыч та җитә дип, өйгә кертеп тә тормадылар. Чоландагы бер чатлыкта утырып калдым. Ә эшләтә белделәр! Авылдан күп итеп ит алып килә башлады болар. Бер бот алалар да ярты ел ашыйлар. Шундый вакытта запас итләрен миңа тутырып куярга өйрәнеп киттеләр. Олыгайды инде бу, ватылыр дип бер дә җәлләп тормадылар. Урамда 30 градус салкын булганда, чоланда ничәне күрсәткәндер, анысын белеп бетермим. Ну, эшләп тә карадым. Башкача тартып булмый бит инде салкында. Тавышларыма кадәр карлыгып бетте. Җитмәсә, и кычкырып утыра инде бу, дип сүгеп китәләр бит әле.

Монысына да түздем. Бервакыт бу йортка да яңа туңдыргыч кайтып төште. Озын буйлы, яңа, чибәр. Ачуың да килмәслек түгел, коридорда булса да, аңа җылыда урын табылды. Тәрәзә янында рәхәтләнеп, тирә-якны манзара кылып утыра бирә. Ул кайткач, миңа чоланда да урын калмады. Гаражга чыгарып куйдылар. Ниләр генә күрмәде анда минем башлар. Киштә булып та хезмәт иттем, шкаф булып та. Хәтерлим әле, нәрсәдер эшләргә осталар килгән иде. Суыткыч дип белделәрме икән, мине кабызып, әбәткә ашый торган ризыкларын куйдылар. Минем эш – катыру бит инде. Кыяр-помидорларын бик җәлләгән идем шунда. Ашый да алмадылар, бахырлар. Тирес өеменә чыгарып аттылар. Шуннан, ачулары килеп, арт ягыма типтеләр. Югыйсә минем ни гаебем бар инде, я?

Бервакыт шулай моңсуланып кына утырам, яныма хуҗабикә белән бер ханым килеп басты. «Менә, кирәк булса, алып кит», – ди хуҗабикә. Сөенергә дә, көенергә дә белмәдем. Зарланырлык булса да, гомер буена яшәгән йортымны ташлап та китәсем килми. Тирә-ягымдагы бөтен әйбер күңелгә якын, таныш бит. Әйбәтрәк булмасмы дип тә өметләнәм. Алып киттеләр. Юк, өметләрем акланмады. Өйгә түгел, гараждагы баскыч астына караңгы урынга кертеп куйдылар. Җитмәсә, дымлы да әле монда. Бөтен җиремнән ага, тама. Кирәк чакта гына кабызгалап алалар да, калган вакытларда моңаеп утыра бирәм.

Их, яшь чакларга, кадерең булган чакларга ни җитә соң? Монда кеше сөйләшкәнне дә ишетмисең бит хәтта. Әле беркөнне шулай да ишетеп калган идем. Сафтан чыга барган суыткыч-туңдыргычларны бер урынга җыялар икән. Запчастька диләрме шунда. Безнең өчен картлар йорты сымаграк урын дип аңладым инде мин аны. Әллә кайчан инде бер апаның елый-елый сөйләгәнен тыңлап утырганым бар иде. Күршедәге ахирәтен улы картлар йортына илтеп куйган. Үзе җир җимертеп яши, ди. Менә мин дә олыгая-олыгая шул язмышка дучар булдым. Хуҗаларым да исән. Гөрләтеп яшәп яталар. Ә мин монда ялгыз каңгырып утырам. Кошларда гына түгел, бездә дә – кеше язмышлары инде, ни әйтсәң дә...

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

«Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советы» ассоциациясе,

улының

кинәт вафат булуы сәбәпле, Татарстан Республикасы Рәисе ярдәмчесе Моратов Равил Фатыйх улының авыр кайгысын уртаклаша.

ЧЕЛТӘРЕНДӘ АДАШМЫЙК

ИНТЕРНЕТНЫҢ ТУГАН КӨНЕ

Интернет ул – чиксез мөмкинлекләр мохите дә, алдау һәм алдану мәйданчыгы да, җәмгыятьне бер үк вакытта алга һәм артка тәгәрәтүче система да... Тормышыбызны аркылыга-буйга чолгап алган виртуаль пәрәвездә ничек адашмаска? Кешелек дөньясы интернет колы булудан туктый алырмы?

Бәйрәм хакында

Интернет 17 майдагы туган көнен 1991 елдан бирле билгеләп уза. Аның «гомер» бәйрәмнәре моның белән тәмамланмый, чөнки мөһим үзгәреш-ачышлар булган тагын берничә датаны билгеләп үтү традициясе бар. Ә менә нәкъ 32 ел элек «Бөтендөнья пәрәвезе»нең стандартлары раслана. Элегрәк әлеге көн программистлар, IT белгечләр һәм, гомумән, шушы өлкәдә эшләүче башка белгечләрнең һөнәри бәйрәме булып саналса, бүген аны кайберәүләр гомумхалык бәйрәме дип тә атый. Аңлашыла да инде: кулларына телефон тотып туган сабыйлардан алып чал чәчле әбекәйләргә кадәр әлеге зур системаның бер өлеше бит хәзер.

Интернетны уйлап тапкан кешеләргә рәхмәт укып туймаслык югыйсә. Күпме белемнәргә, мөмкинлекләргә юл ачты бит алар. Шул ук вакытта интернетның файдасыннан бигрәк зыянын күрүчеләрнең, аны бары тик күңел ачу чарасы буларак кына кабул итүчеләрнең күп булуы уйланырга мәҗбүр итә. Бу хакта блогерлар һәм журналистлар нинди фикердә?

Илдар Мөхәммәтҗанов

Альберт ШАКИРОВ, журналист, блогер:
– Безне, кешеләрне, интернет коллары дип атау яклы түгел мин. Интернет, дөрестән дә, тормышыбызны бик җиңеләйтә. Ә инде анда теләсә нинди, гади итеп әйткәндә, килде-китте мәгълүматның калкып чыгуы – билгеле бер алгоритмнар нәтиҗәсе. Һәм ул алгоритмнар, социаль челтәрләрдә булсынмы, эзләү системаларындамы, кешенең нәрсә белән кызыксынуына, нинди темаларны күбрәк эзләвенә бәйле. Барысы да кешенең дөньяга карашы ни дәрәҗәдә киң булудан тора. Әгәр кеше бик чикле, аерым бер төрле контентка гына өстенлек бирә икән, аның тирәсендәге интернет да шулай формалашачак. Бу аеруча социаль челтәрләрдә нык сизелә. Ә асылда, интернет ул – бик көчле инструмент. Аннан белеп файдаланганда, трендларга иярмәгән очракта, ул шәхес буларак та, профессиональ яктан да үсәргә бихисап мөмкинлекләр ача. Кызганыч, кешене камилләштерә торган контент ул дәрәҗәдә популяр түгел. Ә бит мондый мөмкинлекләр, әйтик, узган гасырда ук булса, без әллә кайчан бик алга киткән булыр идек инде. Адәм баласының ниндидер өлкәләргә генә басым ясап, үзен чикләве аркасында, без шушындый хәлдә катып калдык. Ә бит әллә нәрсәләр майтарырга була!..

Ринат ГАЛИӘХМӘТОВ (Татар малай), блогер:
– Коронавирус пандемиясе башлангач, күпләр өйдә утырды, акчасыз, эшсез калды. Менә шул вакытта өйдә утыручылар акча эшләүнең башка юлларын тапты. Миллионлаган язылучылары булган блогерлар, кешеләрнең өйдә утыруыннан файдаланып, төрледән-төрле марафоннар уйлап чыгара башлады. Блогерлар өчен дә, аларны караучылар өчен дә интернет наркотикка әверелде. Элек без блогларны чын күңелдән алып бара идек, ә хәзер, акча катышкач, бу ихласлык югалды, диимме соң... Дөресен генә әйткәндә, бу – бик куркыныч нәрсә. Социаль челтәрләр акча эшләү чарасы түгел, ә бары күңел ачу чарасы булырга тиеш дип уйлыйм.

Белгеч фикере

Вәсилә ШӘМСЕВӘЛИЕВА, психолог:
– Бүген интернетсыз дөньяны күз алдына китерү кыен. Аның уңай яклары бик күп. Ә инде чынбарлыкны кабул итәргә теләмәгән яки кабул итә алмаган кешеләр виртуаль тормышка чума, тормышындагы ниндидер вакыйгалардан шунда кача. Андый чакта кеше интернет-бәйлелеккә генә түгел, теләсә нинди бәйлелеккә каршы тора алмый башлый. Начар гадәтләр булсынмы, нинди дә булса секталармы, башкасымы – психика өчен нинди бәйлелек булуы мөһим түгел. Качарга гына кирәк. Ә инде кеше үз өстендә эшли, мондый нәрсәләргә каршы тора ала икән, реаль тормышны виртуальдән аера ала икән, ул качып утырмаячак. Интернетны үз файдасына куллана белгән кешеләр өчен аның бер зыяны да юк.

Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА, журналист:
– Яңа технологияләр кеше тормышын җиңеләйтү өчен түгел, ә сугыш өчен уйлап табыла, дип уйлыйм. Интернет та шул максатларда кулланылгандыр. Ул бит иң элек – мәгълүмат туплау һәм алмашу инструменты. Әмма халык аны күңел ачу чарасы буларак кабул итте. Халык белән идарә итүчеләр, бәлки, нәкъ менә шундый максат куеп эш иткәндер дә. Көн саен тамаша теләгән халык уйланмый, укымый, анализламый гына яши, димәк, сорау да булмаячак. Бигрәк тә, кешеләрнең гражданлык позицияләре бик түбән дәрәҗәдә булган илдә. «Тамаша» яратучылар хисабына акча эшләүче ушлы кешеләр интернетны бик оста файдалана. Үткенрәкләр, билгеле, интернет челтәрләрендә рәхәтләнеп сату-алу белән шөгыльләнә. Монысы – дөньяви пәрәвезнең зур плюсы. Уйлап яшәгәннәр өчен мөмкинлекләр ачты ул. Әмма әлегә күпләр өчен интернет инструмент булудан туктап, тормыш мәгънәсенә әйләнде. Кеше тормышын тикшерүдән тәм табып яшәүчеләргә интернетта барлыкка килгән социаль челтәрләр бик кулай булды. Менә шундыйларның күп булуы борчый. Блогерлар, җырчы-блогерлар киңәше үсү өчен мотивация дип әйтүгә, үтерегез, ышанмыйм. Үстерми ул, үз-үзеңне алдый гына. Вакытлыча татлы алдану. Анализлап, укып, нигезләп өйрәнмичә торып бер өлкәдә дә алга китеп булмый. Ә интернетта популяр булган социаль челтәрләр клиплы фикер йөртүне куа. Ягъни карыйсың да икенче минутында ук онытасың. Адәм баласы өчен бу бик куркыныч. Ә инде интернетка үзенә ни кирәген белеп кенә кергәннәр өчен ул – оҗмах. Профессионаллардан нинди генә лекцияләр тыңламыйсың, дөнья музейларын гизәсең, укыйсың-өйрәнәсең, гомумән, минуты-секунды белән соравыңа җавап табасың, файдалы мәгълүмат туплыйсың. Ә инде кол булганнар коллыктан чыга алмас ул. Нигездә, элек телевизор колы булганнар коллыкларын интернетта дәвам иттерә...

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Бу кызык!

✓ Интернет нибары 5 ел эчендә 50 млн кулланучы туплаган. Чагыштыру өчен, радиотапшырулар индустриясенә моның өчен – 38, телевидениегә 13 ел вакыт кирәк булган.
✓ Кытай, Көньяк Корея һәм тагын берничә илдә интернетка бәйлелектән дәвалый торган махсус клиникалар бар икән. Төрле чыганаклардан күренгәнчә, хәзерге вакытта интернет кулланучыларның якынча 6 проценты мондый бәйлелектән интегә. Әлеге «авыру» күбесенчә 15–35 яшьлекләр арасында күзәтелә.
✓ Кешеләр көненә якынча 247 млрд электрон хат җибәрә.
✓ Төньяк Кореяда интернеттан бары хөкүмәт вәкилләре һәм хәрбиләр генә файдалана ала. Мондый катгый чикләүләр булган бердәнбер ил ул.

Авыл хәлләре

«ПЕЧӘН ӨСТЕ ДӘ ҖИТТЕМЕНИ?!»

Елның шушы вакыты җитсә, авыл кешесе иң еш кабатлый торган сүзләр бу. Ел да чалгы тавышын ишеткән беребез диярлек: «Үлә-әм, печән чабар вакыт та җиттемени?!» – дип гаҗәпләнәбез. Ничектер ел да беренче кат печәнне чабар вакыт көтмәгәндә, кинәт кенә килеп җитә кебек.

Язның үзгә мәшәкатьләре, эшләр күп булгангамы икән, әллә инде әле генә «борын төрткән» үләннәр, яңгыры-җылысы булса, көнләп түгел, сәгатьләп үскәнгәме, авылда беренче чалгы тавышы ишеткәч, сискәнеп уянып киткәндәй буласың. Дөрес, әлеге вакыт язның ничек килүенә, табигать шартларына карап, ун-унбиш көнгә соңрак булырга да мөмкин. Тик быелгыдан да иртә була алмый торгандыр.

Кайбер елларда авылда июнь башында, Сабантуйлар җиткәч яки үткәч кенә, моточалгы тавышлары ишетелә башлый иде. Быелгы иртә яз, соңгы яңгырлар үз эшен эшләде: бу көннәрдә инде ара-тирә моточалгы тавышлары ишетелгәли. Дөрес, әле ара-тирә генә. Иң тынгысыз, өлгер хуҗалар гына, бер эш булса да кими торсын дигәндәй, әле печәннең калынлыгы үзләре теләгән кадәр булмаса да, беренче катын чабарга кереште (кемнәрдер малларына көндәлек чабып ашата). Һәр эшкә алдан тотынучы күршеләребез дә ян бакчадагы печәннәрен чапты инде. Без исә, аптырап, гадәтләнгән сүзләрне әйттек: «Печән чабар вакыт та җиттемени?!» Баксаң, инде район хуҗалыкларына да беренче кат терлек азыгы әзерләүгә 25 майдан да соңга калмый керешү бурычы куелган икән.

Илдар Мөхәммәтҗанов

– Соңгы яңгырлар һәм җылылар печәннәрнең үсешен, өлгерешен тизләтте. Кайбер еллардагы кебек, көнгә ничәшәр сантиметр үсә икән дип, печән басуларына линейкалар куясы да юк. Мондый һава шартлары үләннәрне колагыннан тартып үстерә. Берьеллык, күпьеллык үләннәр матур булып өлгереп килә. Кыш буе малларга югары сыйфатлы, энергияле азык ашатам дисәң, аны әзерләүгә мөмкин кадәр иртәрәк керешергә кирәк. Үләннәрне чәчәк атар алдыннан чабып алганда, печән составында файдалы матдәләр күбрәк була, соңга калып җыйганда, алар 40–50 процентка кадәр кими. Күмәк хуҗалык җитәкчеләре, белгечләренә эшне менә шуны истә тотып оештырырга, күләм дип, печәннең калынайганын көтәбез дип, сыйфат мәсьәләсен икенче планга калдырмаска кушылды, – ди белгечләр.

Хәзер инде күмәк хуҗалыкларда печән өстендә, терлек азыгы әзерләү чорында төп авырлык куәтле техникаларга төшә. Кешенең роле – шуларны акыллы, рациональ идарә итү, эшне дөрес оештыру гына. Шуңа күрә техникалар әзерлегенә зур игътибар бирелә, аларны инде күп урыннарда кыр эшләренә керешкәнче үк старт сызыгына куялар. Шунсыз мөмкин дә түгел, Балтач кебек терлекне күп асраган, елдан-ел баш санын арттырган районнарда соңгы елларда терлек азыгы культураларының мәйданнары, аларны үстерүгә, азык әзерләүгә таләпләр дә шуңа пропорциональ төстә арткан. Куәтле «Магдон», «Полесье», «КСК», «Ягуар», «Джондир» комбайннары белән беррәттән, җидешәр-тугызар метрлы яңа типтагы тагылма чапкычлар, заманча әйләндергечләр, тараткыч, җыйгычлар – барысы да терлек азыгы әзерләү чорын тиз һәм җиңелрәк үтәргә мөмкинлек бирә, диләр. Район башлыгы тарафыннан беренче кат уңышны җыйнап алырга 20 көн вакыт бирелгән, гадәттәгечә, ел ярымлык терлек азыгы әзерләү бурычы куелган.

Ә авыл кешесенең – үз сроклары. Кемдер ашыга, кемдер әле үләннәр ныгысын, елдагы вакыт җитсен дип көтә.

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 5313 данә
Гомуми тираж – 14266 данә
Газетага сертификат бирелде Заказ 268

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+